**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

ГЛАВА
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района

Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге
советы
БАШЛЫГЫ

Пер.Совет ур., 44а
Әлкәй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«20» октябрь 2023 ел №3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең Әлкәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 2023 елның 02 ноябрендә 14.00 сәгатькә үткәрергә..

2. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеген Әлкәй торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын үткәрүче - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитеты;

- үткәрү урыны - Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт, Әлкәй авылы Мәдәният йорты;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 21 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 нче йорт адресы буенча урнашкан (авыл мәдәният йорты) мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- сайлау хокукына ия булган, Әлкәй торак тункты халкы исемлеген төзергә ;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Әлкәй торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар. көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);

- территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);

-җирлектә яшәүчеләр өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (Әлкәй авылында парк төзекләндерү);

-халыкны су белән тәэмин итү (эчә торган су линияләрен һәм колонкаларын ремонтлау);

- Әлкәй авылындагы торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны Әлкәй авылы, Совет тыкрыгы, 44а йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Әлкәй авылы, Совет урамы, 34 йорт адресы буенча урнашкан (авыл мәдәният йорты) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: С.З.Зиннурова